25 март - Мәдәният хезмәткәрләре көне

Әйдә, халыкка хезмәткә, хөрмәт эчендә йөзмәккә

Бәйрәмнәрсез тормыш ямьле булмас иде. Көндәлек мәшәкатьләрдән арынып, сәнгать дөньясында ял итүләрне һәр кеше яратадыр. 25 март көнне мәдәният хезмәткәрләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр.

Район, шәһәр тормышын әлеге идарә хезмәткәрләре, алар белән кулга -кул тотынып эшләүче артистлар, биючеләр, сүз осталары, гомумән, сәнгать әһелләреннән башка күз алдына китереп булмый. Иҗтимагый, сәяси вакыйгаларны истә калырлык итеп оештыру, тормышыбызны ямьлерәк итү, халыкка рухи һәм эстетик тәрбия бирү юнәлешендә мәдәният идарәсенең роле искиткеч зур. Аның бурычы - кешеләргә шатлык, кәеф күтәренкелеге бүләк итү, төрле милләт халыкларының рухи һәм милли традицияләрен саклау. Менә ничә ел инде күрсәткечләр буенча Әлмәт муниципаль районы мәдәният идарәсе республикада һәрвакыт алдынгы урыннарны яулый. 25 март көнне һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан, мәдәният идарәсендә районның массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләре белән очрашу булып узды. Чарада идарә җитәкчесе Гүзәл Пайдуллина, үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры Наталья Дугаева, Әлмәт язучылар берлеге рәисе Рәфкать Шаһиев, "Татарстан нефтенең 60 еллыгы" исемендәге парк директоры Флер Кашапов катнашты.

Очрашуны башлап Гүзәл Атласовна Мәдәният елыннан соң Әдәбият елы килүне дәүләт тарафыннан әлеге өлкәгә күрсәтелгән олы игътибар, зур кайгыртучанлык булароак бәяләде.

Бүгенге көндә районда 136 мәдәният, 9 дәүләтнеке булмаган культура - ял итү учреждениеләре эшли, аларда 1017 хезмәткәр исәпләнә. Агымдагы елда төп вакыйгалар, әлбәттә, Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтү һәм Әдәбият елы белән бәйле. Вакыйгалар нигездә шәһәр һәм район китапханәләрендә узачак. План буенча ел дәвамында 1700 дән артык чара уздыру каралган. Төп максат - бигрәк тә яшь буында әдәбияткә карата кызыксыну уяту.

Наталья Дугаева Мәдәният министрлыгы инициативасы белән республикада "Беренче сыйныф укучысының мәдәни көндәлеге" проекты эшләве һәм аның 26 майга кадәр дәвам итәчәге турында сөйләде. Тапшырылган көндәлекләренә укучылар кайчан, нинди мәдәни чарага барганлыклары, катнашканлыклары турында теркәп баралар.

Әдәбият елы буларак, язучыларның да активлыклары арта. Бүлек рәисе Рәфкать Шаһиев сүзләренә караганда, узган ел мәдәният идарәсе, мәктәпләр белән берлектә 323 чара уздырылган булса, быел ул күпкә артык булырга тиеш. Бөтендөнья татар конгрессының Әлмәт бүлеге, "Ак калфак" татар хатын-кызларының Әлмәт бүлеге белән берлектә уздырылган чаралар да яшьләрне әдәбияткә, мәдәнияткә тарту, милли үзаңны үстерүгә саллы өлеш кертә.

Билгеле булганча, үзәк парк әлмәтлеләрнең генә түгел, көньяк- көнчыгыш регионда яшәүчеләрнең дә иң яраткан ял урыны. Иртә яздан караңгы көзгә кадәр ул мәдәни, әдәби тормышның үчагына әверелә. Матбугат конференциясендә Флер Кашапов паркның мөмкинлекләреннән тулырак файдаланырга чакырып, аларның хезмәттәшлек итәргә һәрвакыт әзер булуларын әйтте.

Очрашуны йомгаклап, Гүзәл Пайдуллина киләчәктә дә массакүләм мәгълүмат чаралары белән бер дулкында эшләп, күбрәк халыкны әдәбият, мәдәният белән кызыксындыра алсак иде, дигән теләкләрен җиткерде.

Л. ЗАРИПОВА

"Нәүрүз чибәре-2015"

Гүзәллек, зирәклек, горурлык тантанасы

Күңелләргә биниһая нур, җиһанга матурлык, киләчәк көннәргә ышаныч биреп яз килде. Елның әлеге матур чорында сөйкемлелеге, матурлыгы белән үзенә тартып торган, авылның һәм төбәкнең горурлыгы булган кызлар арасында "Нәүрүз чибәре" бәйгесе уздыру район мәдәният йортының матур һәм күптәнгә традициясе. Быел әлеге чара 20 март көнне Габдрахман авылы мәдәният йортында узды. Матурлыкта, зирәклектә көч сынашырга 13 авылдан гүзәлләр җыелды.

"Нәүрүз гүзәле"н бәяләргә "Альметьевский вестник" газетасы баш мөхәррире, "Ак калфак" татар хатын-кызларының Әлмәт бүлеге җитәкчесе Ландыш Зарипова рәислегендә мәртәбәле жюри да чакырылган иде. Район мәдәният йортының директоры Исламия Ханнанова, танылган алып баручы Рузил Ихсанов, Новоникольск мәдәният йорты директоры Фәридә Хәмидуллина һәм башка абруйлы шәхесләр татар сылуларының тышкы һәм эчке матурлыгын, җырбиюгә, аш-суга осталыгын, модага, кием-салымга мөнәсәбәтен, зәвыклылыгын һәм кыюлыгын, туган телне, гореф-гадәтләребезне ни дәрәҗәдә тирән белүләрен бәяләделәр.

Бәйге "РамАй" дуэты җырлары һәм дөртле биюләр белән башланып китте. Бәйрәмне алып баручы гүзәлләрне сәхнәгә чакырды. Югары Мактама, Яңа Нәдер, Мәмәт, Габдрахман, Кама-Исмәгыйль, Сөләй, Урсалбаш, Колшәрип, Елховой, Кичүчат, Түбән Абдул, Тайсуган, Миннебай, Бишмунча гүзәлләре арасыннан иң-иңен сайлап алу җиңелләрдән булмады.

Беренче турда нәүрүзбикәләр кыскача гына үзләре белән таныштырдылар. Берсе шигырь юллары белән үзен мактаса, икенчесе матур җыр белән теләгәнен әйтеп салды. Икенче бәйгедә кызлар зирәклектә көч сынашып "Бөек Ватан сугышы башлануы турында радиодан кем һәм кайчан хәбәр иткән?", "Әлмәт районының кайсы авылларында, нинди музейлар бар?", "Татарстан Республикасының мәдәният министры кем?" кебек төрле өлкәләргә караган 27 сорауга җавап бирделәр.

Өченче турда осталыкларын раслап бәйгедә катнашучы кызлар тулы бер концерт программасы тәкъдим иттеләр. Дүртенче "Нәүрүз кучтәнәче" дип исемләнгән бүлектә исә гүзәлләр татар халык киемнәрен киеп, үзләре әзерләп килгән татар халык ашларын тәкъдир иттеләр, әзерләү рецепты белән таныштырдылар. Бәяләгән вакытта кызларның туган телләрен яхшы белеп, саф татарча сөйләшүләренә дә игътибар бирелде.

"Нәүрүз гүзәле" бәйгесе җыр-биюләребез, аш-суларыбыз, милли йолаларыбызны чагылдырган олы бәйрәмгә әверелде. Нәүрүзбикәләрнең берсе дә бүләксез калмады. Төрле номинацияләрдә җиңү яулаган кызларга мәдәният идарәсе Дипломнары һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды. Миннебай авылы гүзәле, хәзерге вакытта Риза Фәхреддин исемендәге гимназия укучысы Алсу Мансурова һәрбер уздырылган бәйгедә үзенең иң-иң камил булуын раслап, "Нәүрүз гүзәле" титулына лаек булды. 2 нче урынны Колшәрип авылыннан яшь, талантлы кыз Лиана Ганиева, 3 нче урынны Түбән Абдул авылыннан Айзилә Мозаффарова яулады.

Жюри әгъзалары исеменнән чыгыш ясап, Ландыш Зарипова зал тутырып килгән тамашачыларны бүгенге бәйрәм чарасы белән тәбрик итте. Татар мәдәнияте, татар әдәбиятен пропагандалау, телебезне саклап калу юнәлешендә районда һәм шәһәрдә, шул исәптән район мәдәният йорты тарафыннан киң кырлы эшчәнлек алып барылуын билгеләп үтте. "Ак калфак" оешмасы җитәкчесе буларак, "Нәүрүз гөзәле" кебек милли асылыбызны чагылдырган бәйгеләрнең елдан-ел зуррак масштабларда уздырылуына чиксез шатлануын белдерде.

"Нәүрүз гүзәле"-2015 җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшыру һәм бергәләп фотога төшү белән тәмамланды.

Ф. МИННЕБАЕВА

ПОБЕДА! 70 ЛЕТ

Ветераннар спорттан аерылмый

Әлмәт ветераннары сәламәт яшәү рәвешен актив рәвештә пропагандалыйлар. Муниципаль район җирлегендә оештырылган "Өченче буын"дип аталучы спартакиада агымдагы елда Бөек Җиңүнең 70 еллыгы кысаларында уздырыла.

Спорт эшләрен башлап йөрүче, ветераннар советы җитәкчесенең беренче урынбасары Марсель Надыров сүзләренә караганда, өлкән буын кешеләре ярышларда бик теләп катнашалар, командаларның саны һәм физик әзерлеге елдан-ел арта. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган спартакиада кысаларында Балалар, яшүсмерләр спорт мәктәбендә узган атнада гына шашка һәм шахмат ярышлары булып узды. Интеллектуаль егәрлек бәйгесендә район һәм шәһәребез предприятиеләре ветераннар оешмаларыннан 16 команда (44 ветеран) катнашты.

Көн дәвамында барган ярышлардан соң шахмат ярышлары буенча җиңүчеләр ачыкланды. Соңгы нәтиҗәләр буенча гомуми командалар арасында I урынга- "Әлмәтнефть" идарәсе,

II урынга - "Татнефтегазпереработка" идарәсе, III урынга - "ТМСгрупп" җәмгыяте, IV урынга - "ТН-РемСервис" җәмгыяте чыкты.

Шашка буенча алдынгылыкны УТТ-1, ТН"АЗС-Центр" һәм "Әлмәтнефть" идарәсе ветераннары яулады.

Авыл җирлекләреннән килгән командалар да шәһәрләрдән калышмады. I урынга - Кәләй станциясе, II һәм III урынга - Миннебай авылы спортчылары чыкты. Спартакиада кысаларында ярышлар әле дәвам итәчәк.

Ф. САБАЛЫ